Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлегенең
Миңлебай станциясе гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

13 ноябрь 2025 ел № 1

«Гомуми хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә,Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2025 елның 12 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта узган гражданнарның җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге "Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлеге Миңлебай станциясе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 800 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзүне, ремонтлауны, карап тотуны (юлларга асфальт салуны)?" соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 550 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 335 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 335 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлегенең Миңлебай станциясе гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлеге Миңлебай станциясе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 800 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен: торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзүне, ремонтлауны, карап тотуны (юлларга асфальт салуны)?" турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Миңлебай станциясе, Шоссе урамы, 20а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Миңлебай авыл җирлеге башлыгы И.М. Рәхимов